ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015елның «28» декабреннән № 376

**«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында»**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210 – ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтү өлешендә күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген яңа редакциядә бәян итәргә. (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны түбәндәге мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүматлаштыру бүлегенә әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты**
**җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**

Яңа Чшмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2015елның «28» декабрендәге 376
номерлы карарына
1 нче кушымта

# Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының җирле үзидарә органнары күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге

*Дәүләт хезмәтләре*

1. Тәрбияләнүчеләрне психоневрология тибындагы интернат-йортларга стационар хезмәт күрсәтүгә җибәрү турында карарлар бирү.
2. Суд тәртибендә хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган затка карата опека яисә попечитель билгеләү һәм опекун яисә попечитель билгеләү.
3. Опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт.
4. Балигъ булган хокуктан файдалануга сәләтсез зат мәнфәгатьләрендә торакны хосусыйлаштыруга опекунга рөхсәт бирү.
5. Опекунга үз карамагындагы кешенең фатирын наемга тапшыруга рөхсәт бирү.
6. Тәрбияләнүчеләрнең мөлкәте белән алыш-биреш кылуга рөхсәт бирү.
7. Яшәү урыны алмашынуга бәйле рәвештә, опекунга яшәү урыны буенча теркәлү исәбен алып баруга рөхсәт бирү.
8. Опекунга яисә попечительгә тәрбиядәге баланың нәсел хокукларына керүгә рөхсәт бирү.
9. Опекунга яки попечительгә опекага алынган затның саклык счетыннан файдаланырга рөхсәт бирү.
10. Ятим балалар өчен оешмаларда булган балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү.
11. Балигъ булмаган (алар) исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тартуга алдан рөхсәт бирү.
12. Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка алучыларга кандидат буларак исәпкә кую.
13. Балигъ булмаганнарның күчмә милкен читләштерү буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү.
14. Ундүрт яшькә җитмәгән баланың исемен һәм (яисә) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү.

15. Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны опекага (попечительлеккә) билгеләү яки опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү.
16. Эмансипация турында карар кабул итү (балигъ булмаганны тулысынча эшкә сәләтсез дип игълан итү)
17. Балигъ булмаган яшьтәге күчемсез милекне читләштерү буенча килешүне гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт бирү.
18. Торак сатып алуга кредит акчаларыннан файдаланып алдан рөхсәт бирү һәм аны, балигъ булмаганнар катнашында залогка (ипотекага) тапшыру.
19. Балигъ булмаганның акчалата кертеме алу өчен законлы вәкилгә рөхсәт бирү.
20. Тууны дәүләт теркәве.
21. Никахлашуны дәүләт теркәвенә алу.
22. Никахны өзүне дәүләт теркәвенә алу.
23. Уллыкка (кызлыкка) алуны теркәү.
24. Ата булуны билгеләүне дәүләт теркәве.
25. Исемне үзгәртүне теркәү.
26. Үлемне дәүләт теркәве.
27. Граждан хәле актларын теркәүгә төзәтмәләр яки үзгәрешләр кертү
28. Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында кабат таныклыклар һәм граждан хәле актын дәүләт теркәвенә алмауны раслый торган башка документлар бирү
29. Гражданлык хәле актларын теркәү (юк итү).
30. Дәүләт милкенә кертелгән архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация.
31. Дәүләт милек формасы булган юридик затларга архив эше һәм эш башкаруда документлар оештыру буенча методик һәм практик ярдәм күрсәтү
32. Дәүләт милкенә кертелгән һәм муниципаль архивта сакланган архив документларын муниципаль архивның уку залында эшләү өчен кулланучыга бирү.
33. Дәүләт милкенә кертелгән һәм муниципаль архивта саклана торган архив фондлары буенча архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документларының күчермәләрен бирү.

***Муниципаль хезмәтләр***

1. Торак сатып алу (төзү) өчен социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү һәм учетка кую
2. Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую
3. Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую
4. ЧАЭС радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга дәүләт торак сертификатын исәпкә алу һәм бирү
5. Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм аны кергәндә Дәүләт торак сертификатын бирү;
6. Торак бинаны үзгәртеп коруга һәм (яки) яңадан планлаштыруга рөхсәт бирү.

7. Торак биналарны гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү
8. Муниципаль милектәге гражданга социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү
9. Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урыннарын алмаштыру буенча документларны рәсмиләштерү
10. Торакны торак урыны, торак урынын яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану
11. Торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган бинага күчерү (күчерү) турында хәбәрнамә бирү
12. Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү.
13. Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү
14. Территорияләрнең кадастр планында җир кишәрлеге яисә җир кишәрлекләре схемасын раслау.
15. Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү
16. Җир эшләрен башкаруга ордер бирү
17. Реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү
18. Төзелеп бетмәгән объектны файдалануга рөхсәт бирү.
19. Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү
20. Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару
21. Күпфатирлы торак йортның беренче катында урнашкан фатирда балкон (лоджия) төзелешен килештерү.
22. Инженерлык челтәрләре һәм коммуникацияләр трассалары схемасын килештерү
23. Милекчеләргә һәм кулланучыларга җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектына сак йөкләмәләрен рәсмиләштерү.
24. Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү
25. Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү
26. Агач һәм куаклар кисүгә, кронлаштыруга яки утыртуга рөхсәт бирү
27. Муниципаль берәмлек чикләрендә җирле әһәмияттәге юллар буенча тулысынча яисә өлешчә уза торган маршрутлар буенча авыр йөкләр, зур габаритлы йөкләр ташуларга рөхсәт бирү;
28. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирү
29. Муниципаль учреждениеләргә, муниципаль казна предприятиеләренә оператив идарә итү хокукында һәм муниципаль унитар предприятиеләргә хуҗалык алып бару хокукында муниципаль милекне рәсмиләштерү (беркетү)
30. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген даими (сроксыз) файдалануга бирү
31. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү
32. Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген түләүсез сроклы файдалануга бирү
33. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә генә сату
34. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген сату үткәрмичә арендага бирү
35. Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген, җир кишәрлегендә урнашкан биналар, корылмаларның милекчеләренә милеккә яки арендага бирү

36. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион рәвешендә үткәрелә торган сатуларда арендага бирү
37. Аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда җир кишәрлеге сату юлы белән муниципаль милектәге җир кишәрлеген хосусый милек итеп бирү
38. Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү
39. Муниципаль милектәге җирләрдән яки җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү
40. Крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына муниципаль милектәге җир кишәрлеге бирү (арендага)
41. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү
42. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнарга бакчачылык алып бару өчен милеккә (арендага) бирү
43. Дача хуҗалыгы алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү
44. Хосусый яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген бер категориядәге җирләр составыннан (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) башка җиргә күчерү турында карар кабул итү
45. Җир кишәрлегеннән даими (срокcыз) файдалану хокукын яки җир кишәрлеген гомерлек мирас итеп алу хокукын туктату турында карар кабул итү
46. Җир кишәрлеген сатып алу турында карар кабул итү
47. Күчемсез милек объектларына муниципаль милек реестрыннан өземтә бирү
48. Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсенә үзгәрешләр кертү
49. Муниципаль милек булган җир кишәрлекләрендә хәзинә эзләүгә рөхсәт бирү
50. Муниципаль преференцияләр бирү
51. Документлар күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау
52. Васыятьнамә таныклыгы һәм ышанычнамәләр таныклыгы
53. Белешмә (өземтә) бирү
54. Социаль түләүләрне файдаланып, торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән гражданнар исемлегенә кертү һәм авыл җирлегендә торак төзү (сатып алу) өчен социаль түләү бирү турында таныклык бирү турында
55. Ана (гаилә) капиталы акчаларын җәлеп итеп башкарыла торган шәхси торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләр башкаруны раслаучы документ бирү
56. Милеккә җир кишәрлекләрен түләүсез бирү хокукына ия затлар буларак затларны исәпкә кую
57. Муниципаль милектә булган һәм арендага бирү өчен билгеләнгән күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат бирү
58. Муниципаль казна милкен арендага бирү
59. Муниципаль милектәге җир кишәрлегенә карата сервитут билгеләү турында килешү төзү
60. Элек хосусыйлаштырылган торак биналарны муниципаль милеккә кабул итү
61. Муниципаль милек реестрына керүче муниципаль милекне арендага бирү
62. Җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү

63. Гражданнарның коммерцияле булмаган бакчачылык, яшелчәчелек, дача берләшмәләре әгъзасы булган гражданинга җир кишәрлеген түләүсез бирү
64. Җирлекнең генераль планыннан өземтә бирү
65. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына муниципаль милеккә ия булу һәм (яки) файдалануга тапшыру
66. Гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек, дача берләшмәләренең гомуми файдаланудагы милеккә караган җир кишәрлеген бирү
67. Хезмәт торагын наем шартнамәләре буенча гражданнарга торак урыннары бирү турында
68. Торглар үткәрмичә муниципаль берәмлекнең муниципаль мөлкәтен түләүсез файдалануга тапшыру.
69. Сатулар нәтиҗәсе нигезендә муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану шартнамәсен төзү
70. Объектны урнаштыру урынын алдан килештерү турында карар кабул итү.
71. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмати системасы мәгълүматларын бирү турында
72. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнарга шәхси торак төзелеше өчен милеккә (арендага) бирү
73. Муниципаль милекне арендалауның гамәлдәге килешүен өзү
74. Балаларны мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) исәпкә кую һәм күчерү)